**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 төркем инвалидлардан һәм балачак инвалидларыннан тыш; сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан ветераннардан һәм катнашучылардан, ашыгыч хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән; көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Юлтимир авылы Совет урамы, Игтисамовлар урамында урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Юлтимер торак пунктында Совет ур., Игтисамовлар ур. буенча юлларны чистарту; Юлтимер торак пунктында Совет ур., Игтисамовлар ур. буенча юлларны чокырларга ремонтлау)

3)җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү («Мидхәт чишмәсе»чишмәсен төзекләндерү һәм чистарту);

4)торак пункт территориясен төзекләндерү ( территориядә механикалаштырылган һәм кул белән үләннәр чабу, иске авария хәлендәге агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу));

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк ур., 27 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Сугышлы авыл җирлеге башлыгы А.П.Зыятдинова